КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 16 ноябрь г.Казань № 1025

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны алып юк итүне оештыру һәм башкару турында

«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм терлекчелек продуктларын алып юк итү турында» 2006 елның 26 маендагы 310 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганаклары барлыкка килүне булдырмау һәм аларны бетерү максатларында хайваннарны һәм терлекчелек продуктларын алып юк итүне оештыру һәм башкару тәртибен, Хайваннарны һәм терлекчелек продуктларын алып юк итү нәтиҗәсендә гражданнарга һәм юридик затларга килгән зыянны каплау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хайваннардан эшләнгән продуктлар һәм чималны эшкәртү һәм саклау предприятиеләрендә һәм кошчылык фабрикаларында дәүләт ветеринария күзәтчелеге турындагы нигезләмәне һәм хайваннарның аеруча куркыныч авырулары булганда хайваннарны һәм терлекчелек продукциясен алу тәртибе турындагы тәгълимнамәне раслау хакында» 2002 ел, 29 гыйнвар, 38 нче карарына үзгәреш кертү турында» 2018 ел, 14 февраль, 84 нче карары нигезендә, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны алып юк итүне башкару кирәклеге турында» 2020 елның 7 ноябрендәге чыг-5201 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы вирусы чыккан урыннар барлыкка килүне булдырмау һәм бетерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Буа районының аерым территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән

чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2020 елның 4 ноябрендәге ПУ-725 номерлы Указының 1 пункты белән билгеләнгән территориядә хайваннарны алып юк итүне башкарырга.

2. Бу карарга теркәлгән Хайваннарны алып юк итүне башкару буенча махсус комиссия составын расларга.

3. Хайваннарны алып юк итүне башкару буенча махсус комиссиягә бу карарның 1 нче пункты белән күздә тотылган чараларның үтәлешен билгеләнгән тәртиптә оештырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 16 ноябрь, 1025 нче
карары белән расланды

Хайваннарны алып юк итүне башкару буенча махсус комиссия
составы

| | |
|---|---|
| Мотыйгуллин Габделхак Госман улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары, махсус комиссия рәисе |
| Иванов Евгений Николаевич | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы буенча баш дәүләт ветеринария инспекторы, махсус комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |

Махсус комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әхмәтов Камил Равил улы | «Буа район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы |
| Гатин Идрис Мөдәррис улы | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең дәүләт ветеринария күзәтчелеге бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Гыйззәтов Илдус Гашыйк улы | Буа муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Ногманов Илдар Нургали улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары |
| Сафин Фиргать Мәсгут улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә караган начальник Апас территориаль дәүләт ветеринария инспекциясе бүлеге башлыгы. |